**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6607**
**07.12.2020**

Башкарма комитетның «Муниципаль белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру турында мәгълүмат бирү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 22 маендагы 2614 номерлы карары үз көчен югалтуны тану хакында

Шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2019 елның 31 маенда, 2019 елның 5 июнендә «Челнинские известия» газетасының 38 нче, 39 нчы саннарында, 2019 елның 31 маенда «Шәһри Чаллы» газетасының 38 нче санында басылып чыккан «Муниципаль белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын, шулай ук өстәмә гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыру турында мәгълүмат бирү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 22 маендагы 2614 номерлы Башкарма комитет карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов